Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Урта Балтай авыл җирлеге башкарма комитетының 2022елның 17 гыйнварындагы 2 номерлы «Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Урта Балтай авыл җирлегенең муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертүхакында» карары

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Урта Балтай авыл җирлегенең башкарма комитетыкарар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Урта Балтай авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 12 маендыгы 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Урта Балтай авыл җирлегенең муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1.Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Урта Балтай авыл җирлегенең муниципаль норматив хокукый актлары проектларының (алга таба - актлар проектлары) җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү тәртибен, эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык вазыйфалар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетның нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында муниципаль норматив хокукый актларга (алга таба - норматив хокукый актлар) экспертиза ясау тәртибен (алга таба - норматив хокукый актлар) билгели.»;

1.1 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен яңа таләпләр, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган мәҗбүри таләпләрне үзгәртә торган актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм норматив хокукый актларга экспертиза ясау җирле үзидарә органнары тарафыннан «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, әлеге нигезләмә һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә уздырыла.»;

1.2 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.Түбәндәгеләрдән тыш, эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен яңа яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган мәҗбүри таләпләрне, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычларны билгели торган яисә үзгәртә торган муниципаль хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләнергә тиеш:”;

1.3 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1)җайга салу йогынтысының югары дәрәҗәсе - акт проектында эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен яңа мәҗбүри таләпләр, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычлар билгели торган нигезләмәләр, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә физик һәм юридик затлар чыгымнары законнарында элек каралмаган барлыкка килүгә китерә торган нигезләмәләр;»;

1.3.пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2)җайга салу йогынтысының уртача дәрәҗәсе - акт проектында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен элек каралган мәҗбүри таләпләрне, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычларны үзгәртә торган нигезләмәләр, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә физик һәм юридик затларның законнарда каралган чыгымнарын арттыруга китерә торган нигезләмәләр бар;»;

2.3 пунктының 6 һәм 8 пунктчаларында, 3.5 пунктының 2 һәм 4 пунктчаларында «эшкуарлык, инвестиция эшчәнлеге субъектларының» сүзләрен «эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының, инвестиция эшчәнлеге субъектларының» сүзләренә алмаштырырга;

7.1 пунктының 10 пунктчасында «эшкуарлык, инвестиция һәм (яисә) башка эшчәнлек» сүзләрен «эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек, инвестиция эшчәнлеге» сүзләренә алмаштырырга;

7.1 пунктының 11 пунктчасында «эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге» сүзләрен «эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек, инвестиция эшчәнлеге» сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм Апас муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җирлек башлыгы И.М.Гараев